КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО ОХРАНЕ ОБЪЕКТОВ
КУЛЬТУРНОГО НАСЛЕДИЯ

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МӘДӘНИ
МИРАС ОБЪЕКТЛАРЫН
САКЛАУ КОМИТЕТЫ

---

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

15.12.2021 г.Казань № 328-П

Татарстан Республикасының Кайбыч муниципаль районында урнашкан «Луковское шәһәрлеге» федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объекты террриториясенең чикләрен һәм файдалану режимын раслау турында

“Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләре) турында” 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль закон, “Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында” 2005 елның 1 апрелендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 12 июлендәге 565 номерлы “Мәдәни мирас объектларын саклау буенча Татарстан Республикасы комитеты мәсьәләләре” карары нигезендә боерам:

1. Бу боерыкка 1 кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында урнашкан федераль әһәмияттәге «Луковское шәһәрлеге» мәдәни мирас объектларының чикләрен расларга (бастырып чыгарылырга тиеш түгел).
2. Бу боерыкка 2 кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында урнашкан федераль әһәмияттәге «Луковское шәһәрлеге» мәдәни мирас объектлары территорияләреннән файдалану режимын расларга.
3. Мәдәни мирас объектларын исәпкә алу һәм шәһәр төзелеше эшчәнлеге бүлегенә «Луковское шәһәрлеге» федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектының чикләре турындагы мәгълүматларны Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрына кертүне тәэмин итәргә.
4. Боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Комитет рәисе урынбасары М.М.Вәлиуллинга йөкләргә.

Рәис И.Н. Гущин

Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау комитетының «___» ____ 2021 елның ________боерыгына 2 кушымта

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында урнашкан федераль әһәмияттәге «Луковское шәһәрлеге» мәдәни мирас объекты территориясеннә файдалану режимы

Археологик мирас объектлары урнашкан җир кишәрлекләреннән файдалануның аерым режимы “Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) турында” 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль законда (алга таба - 73-ФЗ номерлы Федераль закон) билгеләнгән тәртиптә, 73-ФЗ номерлы Федераль законның 30 статьясында күрсәтелгән җир, төзелеш, мелиорация, хуҗалык эшләре, ачыкланган археологик мирас объектларының сакланышын тәэмин итү, шулай ук гражданнарның күрсәтелгән объектларга керүен тәэмин итү шартларында урманнардан һәм башка эшләрдән файдалану эшләрен башкару мөмкинлеген күздә тота.

Ачыкланган археологик мирас объектлары урнашкан су объектын яисә аның өлешен куллануның аерым режимы ачыкланган археологик мирас объектларының сакланышын тәэмин итү, шулай ук 73-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә гражданнарның күрсәтелгән объектларга керүен һәм археологик кыр эшләрен уздыруны тәэмин итү шартларында Россия Федерациясе Су кодексында билгеләнгән эшләрне башкару мөмкинлеген күздә тота.